**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өжем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

"04" ноябрь 2019 ел. № 2-2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өжем авыл җирлегенең Таш-Чишмә торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өжем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылы территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өжем авыл җирлеге Таш-Чишмә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

Территорияне төзекләндерү:

- Таш-Чишмә авылында күлне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, Транспорт хезмәтләре өчен түләү һәм эш өчен түләү);
- Таш-Чишмә, Иске Өжем авыллары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту (агач кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү);

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өжем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Өжем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өжем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өжем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.